РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«20» март 2024 ел Олы Кайбыч ав. №249

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының 2008 елның 23 маендагы 138 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы РЕШИЛ:

1. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә хакында» 2008 елның 23 маендагы 138 номерлы Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 9.5 пунктына «, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 28 статьясындагы 3_1 өлешендә билгеләнгән очраклардан тыш,» сүзләрен өстәргә;
- 9.8 пунктында «яисә рекреацион билгеләнештәге зоналарны билгеләү» сүзләрен «, рекреацион билгеләнештәге зоналарны билгеләү яисә торак пункт чикләренең җир кишәрлекләре чикләре белән кисешүен бетерү» сүзләренә алмаштырырга;
- 14.2 пунктта «комиссия» сүзеннән соң «шундый фикер алышулар яисә тыңлаулар тәмамланган көннән алып унбиш эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/ kaybici.tatarstan.ru веб-адрес буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кайбыч муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы Башлыгы
Совет Рәисе А.И.Рәхмәтуллин